ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 1109 «13» 09 2016 ел

Мамадыш муниципаль районында 2016-2017
елларның көзге-кышкы җылыту чоры
башлану турында

Тышкы һава температурасының түбәнәйүе белән бәйле рәвештә, 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы “Җылылык белән тәэмин итү турында” гы Федераль закон, Россия Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы "Җылылык чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында"гы боерыгы һәм Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты кара бирә:

1. Мамадыш муниципаль районында җылыту сезоны 2016 елның 14 сентябреннән башлана дип билгеләргә.

2. «Мамадыш җылылык челтәрләре» ААЖ (Миннәхмәтов Р.Р.) җылыту чоры башланганчы мәгариф, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, сәламәтлек саклау, социаль яклау, мәдәният, физик культура һәм спорт учреждениеләренә җылылык җибәрүне сынап карарга тәкъдим итәргә.

3. «Мамадыш җылылык челтәрләре» ААЖен (Миннәхмәтов Р.Р.), авыл җирлекләре башлыкларына, предприятие һәм учреждениеләр җитәкчеләренә үз балансында котельныйлары булган милек рәвешенә карамастан, җылылык сезоны башлану белән бәйле кирәкле чараларны үтәргә һәм җылылык энергиясен бирүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Ш.М. Сабировка йөкләргә.

Җитәкче И.Э. Фәттахов